**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 23 ноябре 18 номерлы

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026-2027 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында"

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасының Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, башкарма комитет җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026- 2027 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» чыгышын тыңлап, фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026- 2027 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).
2. Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026-2027 елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы рәисе А.Н.Габдрахманов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026- 2027 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2022 Хисап | 2023 Хисап | 2024 Бәяләмә | 2025 фараз | 2026 фараз | 2027 фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халык саны | кеше | 911 | 890 | 870 | 880 | 880 | 880 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 1 | 0,98 | 0,98 | 1,01 | 1 | 1 |
| Мөгезле эре терлекләр саны | баш | 325 | 323 | 304 | 241 | 250 | 260 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,98 | 0,99 | 0,94 | 0,79 | 1,03 | 1,04 |
| Инвестицияләр | мең сум | 2500 | 4690 | 0 | 500 | 530 | 560 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Торак тапшыру | кв.м. | 80 | 80 | 80 | 80 | 80 | 80 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 111925,40 | 139347,10 | 157601,60 | 173204,20 | 189658,60 | 208055,50 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 116 | 124,5 | 113,1 | 110 | 109,5 | 109,7 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 44 204,3 | 55034,40 | 62243,90 | 68406,10 | 74904,70 | 82170,4 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 211 | 211 | 211 | 211 | 211 | 211 |
| Эшкуарлар саны (КФХ,ШЭ) | кеше | 12 | 11 | 10 | 9 | 9 | 9 |
| Эшсезләр саны | кеше | 2 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеген 2024 елның узган чорында социаль-икътисадый үсешнең башлангыч йомгаклары**
**һәм 2024 елда социаль-икътисадый үсешнең көтелгән йомгаклары**

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2024 Январь-сентябрь | 2024 көтелгән |
|---|---|---|---|
| Халык саны | кеше | 870 | 870 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,98 | 0,98 |
| Мөгезле эре терлекләр саны | баш | 241 | 241 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,94 | 0,94 |
| Инвестицияләр | мең сум | 0 | 0 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0 | 0 |
| Торак тапшыру | кв.м. | 100 | 105,6 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 100 | 100 |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 157601,6 | 157601,6 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 113,1 | 113,1 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 62243,9 | 62243,9 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 211 | 211 |
| Эшкуарлар саны (КФХ,ШЭ) | кеше | 10 | 10 |
| Эшсезләр саны | кеше | 0 | 0 |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026- 2027 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәк булган төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

2025-2027 елларга Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2024-2027 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2024 елның көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2025-2027 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен бәяләүне исәпкә алып, 2025-2027 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып эшләнде.

2025-2027 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 69,5-65,9 АКШ доллары дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2025 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 96,5 сум, 2026 елда АКШ доллары өчен 100 сум булыр дип фаразлана. 2027 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 100 сум тәшкил итәчәк.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге составына Иске Минзәләбаш, Кужак авыллары керә.

2025 елга Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә халык саны 880 кеше, 2026 елга – 880 кеше, 2027 елга – 880 кеше тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Җәлил» агрофирмасы ҖЧҖенең булган потенциалын һәм килеп туган үсеш тенденцияләрен, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, шулай ук «Агросәнәгать комплексын үстерү» һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Җәлил» агрофирмасы ҖЧҖ, КФХ Әшрәфуллин И. Р. ,КФХ Сәлимгәрәев Ф. Ф.,КФХ Гарифуллин З. С., КФХ Габдрахманов Р. М., КФХ Леонтьев В.А. эшчәнлек алып баралар.

2024 елда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 1008485,40 сумнан артык тәшкил итәчәк. 2025 ел фаразына караганда, продукция күләме 1058909,60 сум тәшкил итәчәк, 2026 елда – 5% ка артачак һәм 1 111855,10 сум тәшкил итәчәк, 2027 елда – 5% ка артачак һәм 1 167 447,9 сум тәшкил итәчәк.

2024 елда төп капиталга инвестицияләр булмады. 2025 елда грантлар хисабына 0,5 млн.сум күләмендә фаразлана, 2026-2027 елда үсеш темпы 4-5% тәшкил итәчәк һәм 0,53 млн. сум һәм 0,56 млн. сум тәшкил итәчәк.

2025-2027 елларда якынча 200 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2024 елда хезмәт хакы фонды 157 601,6 мең сум тәшкил итәчәк.

2025 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече – 173 204,2 мең сум, 2026 елда – 189 658,6 мең сум, 2027 елда-208 055,5 мең сум тәшкил итәчәк.

Хезмәткәрләр саны уртача 211 кеше тәшкил итә.

2024 елда уртача айлык хезмәт хакы 62 243,9 сум тәшкил итәчәк. 2025 елга фараз буенча ул – 68 406,1 сум, 2026 елда – 74 904,7 сум, 2027 елда 82 170,4 сум тәшкил итәчәк.

2025 елга эшмәкәрләр саны (КФХ) 9 кеше тәшкил итәчәк, 2025 елга-9, 2026 елга-9 кеше.